Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Биектау авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 4**

Биектау ав. 15 нче февраль 2016 ел

«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Биектау авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 25 декабрендәге 22 номерлы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советы карарының үз көчен югалтуын тану турында

Авыл җирлекләре территорияләрендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләрен муниципаль районнарның җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертү сәбәпле, муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты, 3,4 өлешләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 3,5 өлешләре, «Биектау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Биектау авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 25 декабрендәге 22 номерлы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Биектау авыл җирлеге Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Биектау авылы, Х.Сафиуллин урамы, 4 йорт; Околоток-Янгасала авылы, Калинин урамы, 102 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Биектау авыл җирлеге Башлыгы Р.М.Мухаметзянов